3. Журнал «РЖД-туры» январь 2023 год. – URL: https://rzdtour.com/assets/pdf/rzd-mag/RZD_Mag_01_2023.pdf (дата обращения: 28.01.2023).
4. Вести КАМАЗа. – URL: https://www.youtube.com/watch?v=YvNgNVPRuQU (дата обращения: 29.01.2023).
5. Сюжет Вести КАМАЗа. – URL: https://www.youtube.com/watch?v=0SwrOa-4OCk (дата обращения: 29.01.2023).
6. Сюжет Вести КАМАЗа. – URL: https://www.youtube.com/watch?v=lz76advQWpo (дата обращения: 29.01.2023).
7. Сюжет Вести КАМАЗа. – URL: https://www.youtube.com/watch?v=t4p56LPMq6M (дата обращения: 29.01.2023).
8. Сюжет Вести КАМАЗа – URL: https://www.youtube.com/watch?v=NQ3pT3CPpyA (дата обращения: 29.01.2023).
9. Хамидов И.И. // Корпоративные издания как инструмент PR / Вестник Моск. ун-та. Журналистика. – 2009 – № 3. – С. 232-239.

***З.З. Хасанова***
Казанский (Приволжский) федеральный университет
© З.З. Хасанова
***Р.Р.Шамсутдинова***
кандидат филологических наук, доцент
Казанский (Приволжский) федеральный университет
© Р.Р.Шамсутдинова

# ТАТАРСКАЯ ТРЭВЕЛ-ЖУРНАЛИСТИКА (НА ПРИМЕРЕ МАТЕРИАЛОВ РУБРИКИ «ТАТАРЧА WEEKEND»)

# ТАТАР ТРЭВЕЛ-ЖУРНАЛИСТИКАСЫ («ТАТАРЧА WEEKEND» СӘХИФӘСЕ МАТЕРИАЛЛАРЫНА ТАЯНЫП)

***Аннотация.*** *В статье изучается прошлый и нынешний статусы татарской трэвел-журналистики. Эту проблему считаем актуальной, так как именно на татарском языке*

*становится очень мало журналистских работ в данном направлении. Нынешнее состояние татарской трэвел-журналистики авторы рассматривают на примере рубрики «Татарча Weekend» («Татарский Weekend»).*

***Ключевые слова:*** *трэвел-журналистика, рассказы о путешествиях, татарская журналистика.*

***Abstract:*** *This article examines the past and current statuses of Tatar travel journalism. We consider this problem relevant, since it is in the Tatar language that very few journalistic works in this direction become available. The authors of this article examines the current state of Tatar travel journalism using the example of the heading "Tatarcha Weekend" ("Tatar Weekend").*

***Key words:*** *travel journalism, travel stories, tatar journalism.*

Татар журналистикасы җәмгыять белән тыгыз элемтәдә тора. Шуңа да сәяси, рухи һәм дә икътисади сфераларда күзгә күренгән үзгәрешләр бу өлкәдә дә нык чагылыш таба, яңа юнәлешләр, жанрлар барлыкка килә. Глобализация, дигитализация, конвергенция кебек күренешләр журналистларны яңа темалар эзләргә, аларны яңа формада бирү юлларын табарга этәрә.

Хәзерге чор массакүләм мәгълүмат чараларында сәяхәт журналистикасы аерым бер урын алып торган яңа юнәлеш – трэвел-журналистика активлашты. Татарларда бу жанрның башлангычы борынгы чорлардан килә торган тарихы булган сәяхәтнамәләргә барып тоташа. Трэвел-журналистика – хәзерге вакытта журналистиканың иң популяр юнәлешләренең берсе булып торса да, аңа кагылышлы мәсьәләләр тиешле тирәнлектә өйрәнелмәгән.

Татар трэвел-журналистикасы көннән-көн яңара, үсә, замана белән бергә атлый: кәгазь басмаларда гына түгел, ә яңа интернет, телевизион проектлар да чыгып тора. Соңгы елларда татар телеканалларында бик күп яңа проектлар барлыкка килде.

Трэвел-журналистика яшь, урта һәм шулай ук өлкән буынга да кызыклы һәм кирәкле формат. Ул тамашачыга яңа белем бирә, кызыклы урыннар белән таныштыра, күңел ачу функциясен дә башкара.

Трэвел-журналистика (ингл. travel journalism) – журналистиканың үзенчәлекле юнәлеше, ул, тарих, география,

мәдәният, сәнгать, туризм, этика, фәлсәфә һәм башка темаларга кагылып, кулланучыга сәяхәтләр турында мәгълүмат бирә. Тамашачыны башка илләр һәм халыклар белән таныштыра, алар турында беренче күзаллаулар формалаштыра [1]

Трэвел-журналистика бүген тарихи төшенчә булган юлъязмалардан да шактый ерак тора. Хәзерге вакытта ул медиа өлкәсендәге махсус катлам, ул сәяхәт итү, география, мәдәният, тарих, туризм үзенчәлекләре якларын, дин һәм башкалар турында сөйли, аларга карата иҗтимагый кызыксыну уята торган кызыклы мөһим юнәлеш.

Дөньяга интернет таралганчыга кадәр, сәяхәт темасына бары тик профессионаллар гына контент булдырып, башка илләрдә кешеләрнең ничек яшәве, аларның көнкүреше һәм әхлаклары ни белән аерылуы, анда нинди экзотик күренешләрне күзәтергә булуын чагылдыра алган. Өстәвенә, мондый кулъязмалар инде күптән барлыкка килгән, әйтик, Афанасий Никитинның «Хождение за три моря» (борынгы рус әдәбияты әсәре).

Шуңа да карамастан, журналистик юнәлеш буларак ул, бары тик XXI гасырда гына формалашкан. Аннан сәяхәтләр турында хәбәрләрнең мөмкинлеген үстерергә ярдәм итүче очерк һәм юлъязмаларга алмаш булып, интернет, төрле техник җайланмалар, яңа технологияләр килгән, шулай ук кешеләрдә сәяхәт итү ихтыяҗы һәм бу хакта мәгълүмат алу теләге үскән.

Бу күренеш, төрлелек тудырып, һәвәскәр журналистик сәяхәткә трэвел исеме алган (Travel һәм Web дигән ике терминны кушып). Нәтиҗәдә, контент зур популярлык казана, чөнки, гадәттә, мондый мәгълүмат укучыга таныш кешеләр, сылтамалар аша килеп, аларда төрле фикер, ышаныч һәм кызыксыну уята.

Шул вакытта журналистикада билгеле фриланс-язучы, видеограф, фотограф кебек вәкилләрнең уртак эшчәнлеген берләштереп «тревел-журналист» һәм «тревел-блогер» терминнары пәйда була. Алар хис-кичерешләрне мәгълүматка әйләндерүче сәяхәтләр турында тарихи язмалар булдыру белән шөгыльләнәләр. Нәтиҗәдә, трэвел-журналистика медиа киңлегендә география, мәдәният, тарих, дин, туризм, икътисад һ.б. турында тасвирламалардан торган сәяхәтләр турында сөйләүче һәм алар аша мәгълүмат бирүче аерым журналистик катламга әверелә.

Пронин концепциясе буенча, трэвел-журналистикада журналист мәгълүматының берничә үзенчәлеге бар.

- беренче үзенчәлеге – чынбарлык, ягъни мәгълүмат әйләнә-тирә дөньяның кеше белән бәйләнешен чагылдыра;

- икенче үзенчәлеге – универсальлек, журналист мәгълүмат җиткерүнең күптөрле юлларын сайлый ала;

- өченче - идеологик-этик юнәлеш, аның ярдәмендә мәгълүматны кабул итүче мәгълүматны үз дөньясына нигезләнеп үзләштерә [2].

Шулай итеп, терминны ачыклау өчен трэвел-юнәлешләрнең үзенчәлекләрен билгелибез.

1. Трэвел журналистиканың төп максаты башка мәдәниятләрне күрсәтү. Тикшеренүләре күрсәткәнчә, бу яңалыклар туристларда беренче тапкыр очрашырга туры киләчәк ил турында күзаллау формалаштырырга ярдәм итә.

2. Трэвел-журналист этикасы. Сәяхәтләрдән репортажлар редакциядән зур кертемнәр таләп итә, еш кына алар бастырып чыгарган яки күрсәткән материаллардагы чыгымнарны каплый да алмый. Нәшер итүчеләр үз кертемнәреннән табыш, тамашачылардан сәфәр һәм аңа сарыф ителгән акчаларны акларлык уңай фикерләр көтә.

3. Базар шартларына ярашу. Яшәү рәвешен чагылдыручы журналистиканың бу төре үз аудиториясен сатып алучылар сыйфатында күрә. Аудитория, сатып алучы буларак, нәрсә тели, шул максатта тамаша кылу һәм күңел ачуга зур игътибар бирә. Алар фикеренчә, трэвел-журналистиканың максаты – мәгълүматны һәм тәкъдимнәрне күңел ачу һәм ял итү белән катнаштыру. Бу хезмәт күрсәтү функциясенә туры килә, аны шулай ук лайфстайл-журналистика да башкара.

Тапшыруларда алып баручы образы төп роль уйный. Бу шулай булырга тиеш тә, чөнки тапшыру башлангач, иң элек алып баручы һәм аның тышкы кыяфәте, үз-үзен тотышы күзгә ташлана. Моннан аңлашылганча, экран контексты күрү һәм күрсәтү чараларыннан башлана. Телевидениенең өстенлеге – чынбарлыкта булган вакыйганы күрсәтү генә түгел, тамашачыда да әлеге вакыйгада катнашкан, үз күзләре белән күргән кебек хис тудыра алу. Нәкъ менә күрү мөмкинлеге булганга, без тамаша кылучы, ягъни телевизор караучы дип аталабыз. Күрү-күрсәтү

төркеменә: кадр (план), аның төрләре, сөйләм иясенә хас ым, ишарә, мимика һәм хәрәкәтләр чагылышы керә.

Экранга карау белән тамашачы сөйләүченең тавышына һәм интонациясенә игътибар итә. Экран контекстын барлыкка китерүче мондый төр чараларны әйтү һәм ишетүгә бәйле чаралар дип атыйбыз. Бу төркемгә керүче тавыш чаралары икегә аерыла: беренчесе – сөйләүченең шәхси тавышы, икенчесе – өстәмә тавышлар (музыка, ишек шыгырдау, кош сайравы һ.б.) Моңа чагыштырмача охшаш аңлатма телевидение сөйләмен лингвистик (тел) контекст һәм экран контексты юнәлешләренә аерып өйрәнгән Редькина Т.Ю. тарафыннан да бирелгән. Ул экран контекстын шартлыча өч яссылыкта тикшерә [3]:

1) визуаль халәт;
2) аудиохаләт;
3) сөйләм халәте.

Шушы тикшеренүләренең нәтиҗәсе буларак, сөйләм, сурәт һәм синтезны телевизион сөйләм тудыручы өчлек дип атый. Моннан телевидение сөйләмен барлыкка китерүдә тагын бер сөйләм катнашканлыгы аңлашыла.

Сөйләм төрләрен өйрәнүче галимнәрнең телевизион сөйләмне ачыклаучы фикерләре белән танышыйк. Р.С. Нуриев: «Телевидение сөйләменә билгеле бер дәрәҗәдә күпьяклылык хас: ул сүзне дә, шулай ук рәсемне дә (экран) кулланып тудырыла. Телевидениенең асылы шундый – анда мәгълүмат я күрү һәм күзаллау, я аваз һәм тавыш образлары, аларның чиратлашуы яки каршы куелулары аша җиткерелә», – дип искәртә [4].

«Татар социолингвистикасы» хезмәтендә И.М.Низамов «Телевидение сөйләме матбугатныкыннан, радионыкыннан нык аерыла. Аның тәэсир көче язу белән әйтү чараларыннан гына түгел, күрү-күрсәтү чараларыннан да, шул өчлекнең тыгыз, самими үрелүеннән хасил була», – дип яза [5].

Татар телевидениесенең ярты гасырдан артык тарихы бар. Шул вакыт аралыгында телевизион журналистлар тарафыннан хәбәри, аналитик, әдәби-публицистик жанрларда бик күп тапшырулар әзерләп күрсәтелде. 1959 елда нигез салынып, 2002 елдан үз ясалма иярчене аша бөтен дөньядагы татарларны берләштерүче «Татарстан Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе көннән-көн үсә, камилләшә. Аның төп максаты – тамашачы ихтыяҗын канәгатьләндерү. Шул максаттан, төрле форматтагы

һәм төрле жанрдагы тапшырулар барлыкка килә, яңа проектлар тәкъдим ителә. Арада трэвел жанрына якын булганнары да бар: нигездә, өлкәннәр һәм урта буынга юнәлдерелгән «Халкым минем» һәм «Юлчы» тапшырулары һәм яшьләр өчен булган «Яшьләр тукталышы» тапшыруы, «Татарча Weekend» сәхифәсе («Яшьләр тукталышы» тапшыруы кысаларында чыгып килүче).

Бу тапшыруларны анализлаганда, без түбәндәгеләрне исәпкә алдык: жанр, формат, алып баручының эш үзенчәлекләре, контент бирү үзенчәлекләре, алып баручы образы, тапшыруларның динамиклыгын бирү алымнары (стэндаплар, кадрлар тексты, синхроннар, сораштыру, интервьюлар һ. б.)

«ШАЯН» ТВ беренче татар балалар телеканалында һәм «Татарстан-Яңа гасыр» телеканалында чыгучы «Яшьләр тукталышы» тапшыруы кысаларында 2019 нчы елда барлыкка килгән «Татарча Weekend» (инг.weekend – атна азагы, ял көне) сәхифәсе яшьләр ихтыяҗын канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән. Аның максаты – татар яшьләренә үз ялларын үзенчәлекле (аларча әйтсәк, текә), күңелле һәм файдалы итеп уздыру турында мәгълүмат бирү. Иҗади команда (хәбәрче – Талия Төхфәтуллина, оператор – Сергей Малыгин) менә инде өч ел дәвамында республикабызның күп кенә шәһәр-районнарына сәфәр кылып, яшьтәшләренә андагы ял итү урыннары турында сөйли. Тапшыру, гадәттә, позитив стенд-ап белән башланып китә:

*Сәлам-сәлам, сезнең белән татарча weekend сәхифәсе һәм мин Талия. Ышандырып әйтә алам, минем белән сез тиз арада рәхәтләнеп ял итәргә өйрәнерсез!*

Аннан соң алып баручы сәяхәт узасы төбәк белән таныштыра. Ул бу җирлекнең иң матур яисә күпләргә таныш урынында кадр арты тексты һәм видеоманзара аша бирелә:

*Һәм бүген без Татарстанның брендлар башкаласында. Өс киеме, лимонад, табалар һәм бар дөньяга диярлек танылган киез итекләр. Әйе, әйе, дөрес уйлыйсыз, без бүген Кукмарада, дуслар!*

*Ял дигәндә, җәйгә бары тик бер көн калды, димәк, җәйге ял өчен курорт сайлау вакыты җитте! Мин быел үземне бернәрсә белән дә чикләмәскә булдым һәм күңел кая тели - шунда барырга ниятлим!*

*Юк-юк, кинәт кенә баеп та китмәдем, карантинны ябып, чикләрне дә ачмадылар, тагын да яхшырак: мин сезнең өчен иң текә сәяхәт итү сайтлары таптым.*

*Сәлам, тиктормас дусларым! Сез яңа сәяхәткә әзерме?! Алайса, бүген мин сезне республикабызның балык башкаласында каршылыйм. Йә кайсыгыз нинди район турында сүз барганын аңлады?? Әйе, без Лаешка юл тотабыз!*

*Әлеге өяз өчен мөһим һәм әһәмияте булган балыкчылык кәсебе биредә һәрвакыт киң масштабларда алып барыла. Балык, традицион акыл һәм муллык символы буларак, шәһәр һәм өлкә гербларында да сурәтләнгән.*

*Без бүген Арчада! Бу юкка түгел, чөнки Арчабыз быел 90 яшьлек юбилеен билгеләп үтә. Сизәсезме, минем тавышымда күпме соклану, ярату һәм хөрмәт хисләре?! Бу юкка түгел, чөнки мин үзем дә Арчадан һәм бүген Татарстанның иң уңайлы бу шәһәренә сезне дә гашыйк итәргә тырышырмын.*

Мисаллардан күренгәнчә, тапшырулар район яки ял итү үзәгенең башкалардан аерылып торган үзенчәлеген алгы планга чыгару белән башланып китә. Шулай итеп, бу урын яшьләр күз алдында башка яктан ачыла.

Алга таба туризм мәйданында аның урыны, нәрсәләр белән дан казануы, уңышлары җиткерелә, актив яшьләр белән әңгәмә оештырыла, аларның ялларны ничек уздыруы күрсәтелә, нинди дә булса бер шөгыльне алып баручы үзендә сынап карый һәм, үз хис-кичерешләре белән уртаклашып, башкаларга да анда барырга тәкъдим итә. Хәтта монда ял итүнең күпме чыгым таләп итүен дә исәпләп чыгара.

Тапшырулар арасында Арча, Әлмәт, Яр Чаллы, Кукмара, Лаеш, Мамадыш һ.б. районнар, Казан шәһәренең күпләр игътибар да итмәгән кызыклы урыннары турындагы сәхифәләр дә бар. Актив ял урыннары, саф һавада вакыт уздыру өчен уңайлы парклар, кино-театр һ.б. Шулай ук 8 нче март Халыкара хатын-кызлар көне, 23 нче февраль Ватанны саклаучылар көне, 14 нче февраль Гашыйклар көне һәм башка күпләгән бәйрәмнәрне кайта үткәрү мөмкинлеген күрсәткән тематик чыгарылышлар да яшьләрнең табигатенә тулысынча җавап бирә: Мәсәлән, «Сөйгән ярың белән очрашулар өчен топ-3 урын», «Әти-әни белән вакытны үткәрү өчен кызыклы идеяләр» һ.б. лар.

Әлеге сюжетларда трэвел-журналистика элементлары, һичшиксез, бар. Беренчедән, мәгълүмат бирү. Тамашачы, сюжет белән танышкач, үзе өчен күп яңалык ача: матур урыннар,

кызыклы чаралар, вакытны файдалы уздыру. Тапшыруда ул үзенә барлык пунктлар бунча да җавап таба ала.

Икенчедән, яңалык җиткерү: яшьләр игътибарыннан читтә булган урыннарны таныту һ.б.лар. Мәсәлән, Балык Бистәсе районындагы болан фермасы.

Өченчедән, эстетик һәм рухи азык алу. Беркем өчен дә сер түгел: телевизион сюжет караган вакытта тамашачы үзенә рухи азык ала. Мәсәлән, Лаеш районында урнашкан «Семрук» бистәсенең матурлыгына сокланмый мөмкин түгел.

Тагын әле аңа яшьләр өчен мөһим үзенчәлекләрнең берсе интригалылык та хас. Мәсәлән:

*Бүгенге ял төре үз эченә тормыштагы иң рәхәт күренешләрне берләштергән: акыллы хайваннарның берсе белән якыннан аралашу, саф һавада йөрү, җиләс җилнең назын тою, балачактагы кебек тирбәлү, һәм башка күптөрле эмоцияләр кичерү. ... Йә, нәрсә турында сөйләгәнемне аңладыгызмы? Әйе, бүгенге ялны без атлар белән аралашып үткәрербез. Шул максат белән Халыкара ат-спорт комплексына, ягъни Казан ипподромына килдек.*

Экстримлык та тапшыруны яшьләргә якынайта:

*Эх, ни өчен кешеләр дә кошлар кебек очмыйлар икән ул? Менә шулай кулларымны җәер идем дә һәм рәхәтләнеп очар идем.*

Шулай ук трэвел журналистиканың мөһим билгеләреннән берсе – базар шартларына ярашу. Ягъни аудитория, нәрсә тели, шуны тәкъдим итү. Әйтик, актив ял бүген яшьләрне кызыксындырган төп өлкәләрнең берсе. «Татарча Weekend» сәхифәсе шул максатта тамаша кылу һәм күңел ачуга зур игътибар бирүе белән дә игътибарга лаек. Ул мәгълүматны күңел ачу белән бергә кушып җиткерә. Безнеңчә, бу тапшыру youtube платформасында да урнаштырылса, Татарстан туризмын пропагандалау юнәлешендә зур эш башкарылыр иде.

Шулай ук «Яшьләр тукталышы» тапшыруы өчен Санкт-Петербургка биш көнлек сәфәр вакытында Зөлфия Хәсәнова һәм Наилә Закирова тарафыннан төшерелгән сюжетларны да без татар-трэвел журналистика үрнәге буларак карый алабыз. Шәһәрнең кызыклы, истәлекле урыннары, популяр ризыклары, бай тарихы, андагы яшьләр тормышы, милләттәшләребезнең тормыш-көнкүреше турындагы бу сюжетлар, телефон

камерасына гына төшерелгән булса да, югары сыйфатлы һәм кызыклы форматта тәкъдим ителүе белән игътибарга лаек.

Сәяхәт барышында төрле урында төшерелгән стендап (беренче локация: Казан халыкара аэропорты – Санкт-Петербург «Пулково» аэропортында төшерелгән). Алар кыска, позитив, анда жестлар, мимикалар, эмоцияләр дә ташып тора:

*Сәлам дуслар, мин – Зөлфия, мин – Наилә һәм без бүген илебезнең төньяк башкаласына кечкенә генә сәяхәткә чыгабыз.*

*Без очабыз, сау бул Казан!*

*Менә без Питерга килеп җиттек. Ул безне кояш белән каршы калды. Ә нәрсә безне монда көтә, сез алда белерсез.*

*Әйе, ялларны без Питерда үткәрдек. Ләкин монда без ял итеп кенә калмадык, ә сезнең өчен күпләгән кызыклы урыннар әзерләдек. Хәтта читтә яшәүче милләттәшләребез белән дә танышырга өлгердек.*

Тапшыруның буеннан-буена алмашынып торучы стендап һәм сюжетлар хәрәкәте, шәһәр күренешләре, фотосурәтләр дә укучы күз алдында Санкт-Петербург шәһәренең тулы картинасын булдыра.

Шунда ук кадр арты тавыш белән сәяхәткә кыска гына «экскурс» та ясалып бара. Гадәттә, Санкт-Петербуг турында сөйләгәндә, Эрмитаж, гаҗәеп чиркәүләр, музейлар телгә алынса, бу юлы кызлар шәһәрнең артык популяр булмаган башка урыннарына тукталу максатын куйганнар. Тапшыруда «Питер буйлары» оешмасы (икенче локация), Петр беренченең ботаника бакчасы (өченче локация), метро (дүртенче локация), «Севкабель» порты (дүртенче локация), Александринский театры (бишенче локация), Санкт-Петербург түбәләре һ.б. урыннар белән бәйле сюжетлар төп урын алган.

Ә кадр арты текстларында бу тарихи урыннар турында мәгълүмат кына бирелеп калмый, авторларның аларга мөнәсәбәте, хисләре дә җиткерелә.

Гомумән, локацияләр күптөрле һәм еш алышына. Һәр видеоязмада 4-5 локация, алар турында аңлатмалар урын ала. Шуңа күрә кызлар алып баручы гына түгел, ә экскурсовод, гид ролен дә үти. Бу аңлашыла да, трэвел-сюжет – экскурсия, ә, димәк, тамашачылар – тыңлаучы/катнашучы/туристлар. Шуңа күрә дә авторларның әлеге объектлар турындагы мәгълүматтан хәбәрдар булуы һәм аның турындагы мәгълүматны аудитория

ихтыяҗларына яраклаштырып җиткерүе дә игътибарга лаек. Мәсәлән, Ботаника бакчасында үсемлекләрнең күптөрлелеге, аларның зурлыклары һ.б. «Севкабель» портында бәяләрне әйтеп китү, товар ассортиментын күрсәтү; Николай беренченең тормыш иптәше Александра Фёдор кызы исемен йөртүче беренче профессиональ рус драма театры «Александринский театр»ның гаҗәеп бинасы, анда Николай Васильевич Гогольның «Женитьба» әсәре куелышына күзәтүләр дә яшьләрдә кызыксыну уятмый калмагандыр.

Тапшыруның төп үзенчәлекләре дип түбәндәгеләрне атый алабыз:

1. Төшерелеш. Съемкада, кызлар алып баручы ролен дә үти, оператор да үзләре. Техникадан телефон һәм микрофон гына кулланылган. Гади кадрлар – «1х» режимында, ә зур объектлар, шәһәр күренешен төшергәндә – «0,5х» режимы кулланылган. Нәтиҗәдә ул кадрга зуррак мәйданны алырга мөмкинлек биргән. Шулай ук объектны якыннанрак төшерер өчен зум, статик кадрлар өчен куллар ярдәм иткән. Съемка барышында «влог» форматы өчен төп һәм фронталь камера белән дә эшләгәннәр.

2. Монтаж. Монтаж вакытында берничә уңышлы алым кулланылган: Хәбәрче сөйләгән вакытта фон музыкасы – тынычрак тонда, ә видеоряд барганда, киресенчә, кызурак. Ягъни кадрлар музыканың ритмына һәм темпына туры китереп төзелү нәтиҗәсендә тапшыру «клиповый монтаж» ны хәтерләтә. Бу шәһәр атмосферасына тирәнрәк чумарга ярдәм итә. Шулай ук вакыт-вакыт кадрларның тизлеген арттыру алымы да кулланылган. Мәсәлән, хәбәрче каядыр барганда, яки юлны автобус тәрәзәсеннән күрсәтеп бару вакытында. Тагын бер алым – кызыклы мизгелләргә игътибар итү. Аларны «ляплар» дип атыйлар һәм, гадәттә, аларны кисеп атарга ашыгалар. Ләкин нәкъ менә трэвел-журналистикада алар үз урынын ала ала. Мондый кадрлар тамашачыга хәбәрче белән бергә булырга, юмор тудырырга да ярдәм итә.. Кадрларны аеру өчен аклы-каралы фильтр кулланылган.

3. Форматлар. Кайбер кызыклы фактларны кадр арты тавыш белән әйтеп китү, «клип монтажы» алымы, блогерларга хас влог форматы һ.б.лар аша кызлар тамашачыга якынрак булырга тырыша һәм алар белән тыгыз элемтә урнаштыра. Камерага карап сөйләү нәкъ менә дустың белән табигый аралашу

төсмере тудыра, нәтиҗәдә сюжет, әңгәмә гади, ихлас килеп чыга. Яшьләргә мәгълүматны кабул итү өчен бу бик уңайлы формат. Алар яңа мәгълүмат та ала, вакытны да файдалы уздыра, шулай ук «дусты» белән дә аралашырга өлгерә.

4. Маҗаралылык. Трэвел-журналистикага кагылышлы күпләгән проектларда хас бу үзенчәлек тә тапшыруга хас алым. Тамашачыга хәбәрчеләр белән бергә сәяхәткә «бару» тәкъдим ителә һәм аңа онлайн рәвештә яңа урында булу мөмкинлеге тудырыла. Ул хәбәрче белән бергә ашый, матур урыннарны күрә, тарихи объектларны өйрәнә. Нәтиҗәдә, видеоязмаларны карагач, кешенең анда булу теләге уяна һәм ул үзе өчен күп файдалы мәгълүмат ала, чөнки трэвел-журналистиканың максаты күңел ачу гына түгел, ә мәгълүмати контент өстәү дә.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, позитив юнәлешкә нигезләнгән, татар халкының әхлаклылыгын, яшәү рәвешен, мәдәниятен, тарихын яктыртып килүче «Татарстан - Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе бүген үсештә, үзгәрештә. Спутниклы канал булу мөмкинлеге аны төрле төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребезгә дә карау мөмкинлеге бирә һәм татарларны таныту, татар дөньясын үстерү өстендә эшли. Трэвел журналистика юнәлешендәге тапшырулар да әлеге максатны чынга ашыру юлында зур эш башкаралар.

**Әдәбият:**

1. Лучинская С.Ю. Журналы-травелоги на российском медийном рынке: автореф. дис... канд. фил.наук. Краснодар, 2009. 22 с.

2. Лазутина Г.В. Основы творческой деятельности журналиста. Учебник для вузов. М.: «Аспект Пресс», 2001. 240 с.

3. Редькина Т.Ю. Этические и речевые нормы в трэвел-медиатексте // Экология языка и коммуникативная практика. 2014. № 1. С. 150-160.

4. Нуриев Г.С. Сәнгатьле сөйләм: Уку ярдәмлеге. Казан: Мәгариф,2009. 199 б.

5. Низамов И. М. Татар соцолингвистикасы. Казан: Казан дәүләт унты нәшр., 2006. 152 б.